**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 елның 4 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 7 июнендәге ПУ-400 номерлы, 2022 елның 31 августындагы ПУ-611 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 3 апрелендәге 194 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Украина Кораллы Көчләре подразделениеләренең Курск өлкәсенә корал кулланып бәреп керүен кире кайтару бурычларын үтәү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләрнең.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 06 ноябрь
№ 852